КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 2 февраль г.Казань № 54

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 31 октябрь, 988 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориаль иҗтимагый үзидарә системасын үстерүгә юнәлдерелгән чараны уздыруга территориаль иҗтимагый үзидарәләр җитәкчеләренә компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру өлешендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориаль иҗтимагый үзидарә системасын үстерүгә юнәлдерелгән чараны уздыруга территориаль иҗтимагый үзидарәләр җитәкчеләренә компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру өлешендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 31 октябрь, 988 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 11 август, 793 нче; 2022 ел, 30 декабрь, 1469 нчы, 2023 ел, 19 сентябрь, 1161 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориаль иҗтимагый үзидарә системасын үстерүгә юнәлдерелгән чараны уздыруга территориаль иҗтимагый үзидарәләр җитәкчеләренә компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру өлешендә Татарстан Республикасы муниципаль

берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә, 9 пунктның беренче абзацында «елның 15 гыйнварыннан соңга калмыйча» сүзләрен «елга кадәрге елның 1 декабреннән соңга калмыйча» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин